Карар

26 гыйнвар, 2026 ел № 1

**Татарстан Республикасы Кукмара районы Зур Сәрдек авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга су белән тәэмин итү схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара районы Зур Сәрдек авыл җирлеген 2035 елга кадәр чорга су белән тәэмин итүнең кушымта итеп бирелгән схемасын расларга.

2. Әлеге карарны Зур Сәрдек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» челтәрендә Кукмара районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл
җирлеге башлыгы Ф.М. Фәттахов

ОГРН 1021607753232
ИНН 1623001727

Зур Сәрдек авыл җирлеге
башлыгының 2026 елның 26
гыйнварындагы номерлы карары
белән РАСЛАГАН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

# КУКМАРА РАЙОНЫ ЗУР СӘРДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕН

# 2035 ЕЛГА КАДӘР ЧОРГА СУ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ СХЕМАСЫ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеген су белән тәэмин итү схемасы – су белән тәэмин итү системасының нәтиҗәле һәм имин эшләвен, аны хокукый җайга салуны исәпкә алып үстерүне нигезләү буенча материаллар булган документ.

Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеген су белән тәэмин итү схемасын эшләү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1. «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон;
2. РФ Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемалары турында» 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карары.

Су белән тәэмин итү схемасы территориаль планлаштыру документлары һәм җирлекнең коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү программалары нигезендә эшләнә.

Су белән тәэмин итү схемасы 10 елга эшләнгән.

## II. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасының төп максатлары һәм бурычлары

- техник мөмкинлеге булганда, мондый тоташтыруны башкарырга тиешле капиталь төзелеш объектын һәм оешманы су белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру мөмкинлеген билгеләргә;

- норматив таләпләр нигезендә су белән тәэмин итү системаларының ышанычлылыгын арттырырга;

- озак сроклы перспективада һәр кулланучыга исәпләгәндә су белән тәэмин итүгә чыгымнарны минимальләштерергә;

- Зур Сәрдек авыл җирлегендә яшәүчеләрне су белән тәэмин итү челтәренә тоташтыру һәм җирлектә яшәүчеләрне хуҗалык-эчү билгеләнешендәге су белән тәэмин итү зарур булганда тәэмин итәргә.

## 1 бүлек. Җирлек буенча су белән тәэмин итү турында белешмәләр

### 1. Татарстан Республикасы Кукмара районы Зур Сәрдек авыл җирлегенә кыскача характеристика

Зур Сәрдек авыл җирлеге чиге «Территорияләр чикләрен билгеләү һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә кабул ителде (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән).

Зур Сәрдек авыл җирлеге составына әлеге закон нигезендә түбәндәгеләр керә: Зур Сәрдек авылы, Чишмәбаш авылы, Купка авылы, Адай авылы, Аш-Буҗи авылы, Кара-Елга поселогы.

Зур Сәрдек авыл җирлеге Татарстан Республикасы Кукмара районында Кукмара шәһәреннән 20 км төньяк-көнбатышта урнашкан.Зур Сәрдек авыл җирлеге Сәрдекбаш, Олыяз, Зур Кукмара, Күкшел авыл җирлекләре белән чиктәш.

2025 елның 01 гыйнварына Зур Сәрдек авыл җирлегендә халык саны – 3370 кеше.Административ үзәге – Зур Сәрдек авылы.

Авыл җирлеге чикләрендәге территория мәйданы – 6960 га. Территориянең район үзәге белән төп тышкы транспорт элемтәсе булып Кукмара – Трыш автомобиль юлы тора.

Зур Сәрдек авыл җирлегенең шәһәр барлыкка китерү базасы нигезен «Восток Агро» ҖЧҖ» тәшкил итә. Аграр сектор үз эченә шулай ук 6 крестьян-фермер хуҗалыгын һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны ала.

Хуҗалыклар эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып, бөртекле культуралар, бәрәңге, яшелчә үстерү, терлекчелек тора.

Рельефы – сөзәк-калкулыклы тигезлек. Хәзерге эрозия процесслары рельефка сизелерлек йогынты ясаган. Районның геологик төзелеше аның Рус платформасы, 2 км тирәнлектә урнашкан кристаллик фундамент кебек тектоник структурага туры килүе белән аңлатыла. Утырма токымнарның калынлыгы девон, ташкүмер һәм Пермь системалары катламнарыннан гыйбарәт. Мәйданны бер геоморфологик элемент алып тора, аз бүленгән, Геологик кисем литологиясе буенча катламнары куәтләре һәм җәелүләре буенча тигез ятмаган дүрт катламнан артмый, сулы горизонт юк, үзенчәлекле грунтлар киң таралыш тапмаган. Өйрәнелгән мәйдан чикләрендә билгеләнгән үзенчәлекле грунтларга өемле грунтларны һәм пермь яшендәге элювиаль грунтларны кертергә кирәк. Зонада элювиаль грунтлар су бүленешләре битләрендә өемле грунтларның аз куәтле тышчасы булып таралган, күбесенчә чуар төстәге каты, ярым каты балчыктан тора, физик җилләнүгә кагылган структур элювий катламына кертелгән. Потенциаль су басу дәрәҗәсе буенча территория потенциаль су басу территориясенә керә.Грунтларның корыч конструкцияләргә карата коррозия активлыгы югарыдан уртачага кадәр үзгәрә. Өске карст катламы юк.Бу районда сөзәклек эрозиясе зәгыйфь һәм уртача интенсивлыкта.

Климаты уртача-континенталь, кышы салкын, җәе җылы. Климатик район – 1В. Тышкы һаваның исәпләнгән температурасы – минус 32 С, ел фасыллары ачык чагыла. Норматив җил басымы – 30 кг/кв.м.Исәпләнгән кар йөкләнеше – 240 кг/кв.м. Туфрак туңуның норматив тирәнлеге – 1,7 м. Климат өчен ел фасылларының күчеш чорлары кискен алмашыну, озын салкын кыш һәм уртача җылы җәй хас. Чагыштырмача тигез, аз гына калкулыклы рельеф һәм тау киртәләренең булмавы Атлантик океаннан һава агымнарының ирекле үтеп керүенә ярдәм итә, бу исә кышның кырыслыгын киметә. Язын ккөньяк һәм Төньяк юнәлешләрдәге җилләрнең киңлекара алмашынуы көчәя. Бу язын тотрыксыз температура режимын тудыра. Май-июнь айларында салкыннарның кабат кайтуы һәм хәтта кар явуы күзәтелә.

Җирлекнең төп табигый ресурслары булып хуҗалык-эчү билгеләнешендәге җир асты геотермаль сулары тора.

Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә 9 скважина һәм 10 су башнясы урнашкан, алар Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты милкендә.

## 2. Проект карарлары.

Зур Сәрдек авыл җирлеген су белән тәэмин итүнең проект чишелешләре, челтәр һәм корылмаларның факттагы торышын исәпкә алып, эшләнә торган Генераль план нигезендә ихтыяҗның артуы нигезендә гамәлдәге барлыкка килгән су белән тәэмин итү системасы нигезендә нигезләнә.

Җирлекне су белән тәэмин итү системасы үзәкләштерелгән, хуҗалык-эчү системасы – билгеләнеше буенча, тупик системасы – конструкциясе буенча.

Халыкка эчәрлек сыйфатлы су бирү хуҗалык-эчү ихтыяҗларына һәм су сибүгә, җитештерү предприятиеләренең технологик ихтыяҗларына, янгын сүндерүгә каралган.

## 3. Су белән тәэмин итү чыганаклары, су белән тәэмин итү схемасы.

### Зур Сәрдек авыл җирлеген үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының техник-икътисадый торышы

Зур Сәрдек авыл җирлегенең үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасы Зур Сәрдек авыл башкарма комитеты милкендәге 9 артезиан скважинасына һәм 10 су җыю манарасында (күләме 25 куб. м) нигезләнә.

Су белән тәэмин итү түбәндәге торак пунктларда гамәлгә ашырыла: Зур Сәрдек авылы, Чишмәбаш авылы, Купка авылы, Адай авылы, Аш-Буҗи авылы, Кара-Елга поселогы. Зур Сәрдек авыл җирлегендә торак төзелеше шәхси торак йортлардан гыйбарәт.

**Зур Сәрдек авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Тау асты ур., 15б адресында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1978 елда 60 м тирәнлектә бораулаган.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Зур Сәрдек авылында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 10950 м3 (тәүлегенә 30,0 м3) тәшкил итә.

Зур Сәрдек авылы торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Суүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 13,5 км. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Зур Сәрдек авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Зур Сәрдек авылы, Мәктәп яны ур., 8б адресында

урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1982 елда 50 м тирәнлектә бораулаган.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Зур Сәрдек авылында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 11315 м3 (тәүлегенә 31,0 м3) тәшкил итә.

Зур Сәрдек авылы торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Суүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 14,2 км. ЭЦВ 5-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Чишмәбаш авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Чишмәбаш авылы, Яшьләр урамы, 27б адресында урнашкан су скважинасыннан башкарыла. Скважина 1980 елда 60 м тирәнлектә бораулаган.

Скважина тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Чишмәбаш авылының хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 7994 $м^3$ (тәүлегенә (21,9 $м^3$ ) тәшкил итә.

Чишмәбаш авылы торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR диаметрлы суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт, аның гомуми озынлыгы 9 км тәшкил итә. Файдалануга тапшыру елы – 1980. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме – 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Чишмәбаш авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Чишмәбаш авылы, Посадка урамы, 57 адресында урнашкан су скважинасыннан башкарыла. Скважина 2023 елда 70 м тирәнлектә бораулаган.

Скважина тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Чишмәбаш авылының хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 3979 $м^3$ (тәүлегенә (10,9 $м^3$ ) тәшкил итә.

Чишмәбаш торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR диаметрлы суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт, аның гомуми озынлыгы 3,6 км тәшкил итә. Файдалануга тапшыру елы – 2023. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме – 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик

состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Кара-Елга авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кара-Елга авылы, Үзәк ур., 23б адресында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1980 елда 50 м тирәнлектә бораулаган.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Кара-Елга авылының хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 5475 $м^3$ (тәүлегенә 15,0 $м^3$) тәшкил итә.

Кара-Елга авылы торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Суүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 1,1 км. Төзелгән датасы – 1980 ел. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

Купка авылы торак пунктын су белән тәэмин итү түбәндәге адреста урнашкан ике су алу скважинасыннан башкарыла: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Купка авылы, Пролетар ур., 14а. Скважина 1976 елда 80 м тирәнлектә бораулаган.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Купка авылы торак пунктында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 11495 м3 (тәүлегенә 30,67 м3) тәшкил итә.

Купка авылы торак фондының суүткәргеч челтәре диаметры 63 мм булган ПЭ100SDR суүткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Суүткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 8 км. Төзелгән датасы – 1976 ел. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Аш-Буҗи авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Аш-Буҗи авылы, Яшьләр ур., 35б адресында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1978 елда 60 м тирәнлектә бораулаган.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Аш-Буҗи авылы торак пунктында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 11445 куб м (тәүлегенә 31,4 куб м) тәшкил итә.

Аш-Бужи авылы торак фондының сууткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR сууткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Сууткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 5,5 км. Төзелгән датасы – 1978 ел.ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Аш-Бужи авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Аш-Бужи авылы, Басу ур., 30б адресында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1978 елда 60 м тирәнлектә бораулангaн.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Аш-Бужи авылы торак пунктында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 12000 м3 (тәүлегенә 32,9 м3) тәшкил итә.

Аш-Бужи авылы торак фондының сууткәргеч челтәре диаметры 110 мм булган ПЭ100SDR сууткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Сууткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 7,5 км. Төзелгән датасы – 1978 ел. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

**Адай авылы торак пунктын су белән тәэмин итү** Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Адай авылы, Яшьләр ур., 7б адресында урнашкан су алу скважинасыннан башкарыла. Скважина 1979 елда 70 м тирәнлектә бораулангaн.

Скважиналар тамагы павильон белән ябылган. Санитар сак зонасының беренче поясы коймасы бар. Скважинадагы су өсте тигезлегенең торышын һәм алына торган суның күләмен күзәтү алып барылмый. Су Адай торак пунктында хуҗалык-эчү ихтыяҗларына кулланыла. Суга ихтыяҗ елына 10001 м3 (тәүлегенә 27,4 м3) тәшкил итә.

Адай авылы торак фондының сууткәргеч челтәре диаметры 63 мм булган ПЭ100SDR сууткәргеч торбалар системасыннан гыйбарәт. Сууткәргеч челтәренең гомуми озынлыгы 9 км. Төзелгән датасы – 1979 ел. ЭЦВ 6-10-110 насосының өзлексез эшләвен идарә автоматикасы тәэмин итә. Су башнясының күләме 25 куб. м. Җир асты суларының сыйфаты өйрәнелгән химик состав күрсәткечләре һәм микробиологик күрсәткечләр буенча СанПиН 2.1.4.1074-01 «Эчә торган су» норматив таләпләренә туры килә.

Халыкны хуҗалык һәм эчәр су белән тәэмин итү мәсьәләләре белән Зур Сәрдек авыл җирлеге администрациясе шөгыльләнә. Су белән тәэмин итү чыганагы булып җир асты сулары тора. Су чыгару өчен тирән сулы артезиан скважиналары, чистарту корылмалары, зарарсызландыру җайланмалары, оештырылган һәм төзек санитария зоналары булмаган каптированный чишмәләр файдаланыла.

Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу корылмаларын модернизацияләү һәм төзү гаять түбән темплар белән башкарыла. Халыкка бирелә торган суның сыйфаты канәгатьләнерлек булмавының бер сәбәбе –сүүткәргеч челтәрләрнең нык тузганлыгы. Челтәрләрнең иң нык тузганы урамдагы сүүткәргеч челтәрләренә туры килә. Күп кенә югалтулар, сүүткәргеч суның агып чыгуы челтәрләрнең һәм җиһазларның нык тузуы аркасында килеп чыга.

Зур Сәрдек авыл җирлегенең су белән тәэмин итү системасы хуҗалык-эчү һәм янгынга каршы ихтыяҗлар өчен территориаль планлаштыру, расланган схема, җирлекнең генераль планы, «Кукмара муниципаль районының коммуналь инфраструктура системаларын комплекслы үстерү» программасы нигезендә планлаштырыла. Хуҗалык-эчә торган су белән тәэмин итү өчен җир асты сулары кулланылачак.

Хәзерге сүүткәргеч челтәрләренең һәм корылмаларының техник торышы, аларны озак вакыт файдалану сәбәпле, эчәргә яраклы сыйфатлы су әзерләү дәрәҗәсен киметә. Ремонт һәм реконструкция таләп ителә. Су эчә торган су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелмәгән һәм үзәкләштерелгән системалары нормалары таләпләренә җавап бирергә тиеш.

## 4. Җирлек буенча үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының төп проблемалары:

1. Кайбер су белән тәэмин итү объектларының санитария нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килмәве (су белән тәэмин итү системаларының гигиена нормативлары нигезендә суның тотрыклы сыйфатын тәэмин итәргә мөмкинлек бирми торган санитария-техник торышы канәгатьләнерлек түгел).

2. Санитария саклау зоналары булмау, йә аларның пояслары чикләрендә тиешле режимны үтәмәү, нәтиҗәдә су белән тәэмин итү чыганакларына пычраткыч матдәләр һәм микроорганизмнар эләгү ихтималы аркасында аларның санитария ышанычлылыгы кими.
3. Кулланучыларга су бирә торган сүүткәргечләрдә кирәкле чистарту корылмалары (зарарсызландыру җайланмалары) комплексы булмау.
4. Су чистартуның заманча технологияләре булмау.
5. Баш корылмаларның һәм челтәрләрнең бик нык искергән булуы.
6. Куллану урыннарына илтеп җиткерү процессында суның күп югалтылуы.

Зур Сәрдек авыл җирлеге торак пунктларын су белән гарантияле тәэмин итү өчен, тулысынча төзекләндерелгәндә (һәр йорт, җәмәгать биналары һәм коммуналь билгеләнештәге биналар эчендә сүүткәргеч челтәрләр урнаштыру) киләчәктә искә алырга кирәк:

1. хәзерге вакытта авария хәлендә булган тирән су скважиналарын, технологик җиһазларны алыштырып һәм оголовокны ремонтлап, капиталь ремонтлау, кайбер чараларны башкарырга: насосны һәм тирә-як торбаларны сүтәргә, ике тәүлек дәвамында эрлифт белән су үткәрергә;
2. җирлекнең барлык торак пунктлары территориясендә гамәлдәге сүүткәргеч челтәрен үстерү Ø110÷63мм;
3. гамәлдәге челтәрләрне этаплап реконструкцияләү.

Суүткәргеч челтәрен Ø110÷63 мм киләчәккә ПЭ100 SDR17 ГОСТ 18599-2001 полиэтилен торбалардан планлаштырырга кирәк.

Биналарга керү юлларында су үлчәү узеллары җайланмасын СниП 2.04.01-85* нең «Биналарның эчке суүткәргече һәм канализациясе» 11 бүлеге нигезендә проектларга.

Су чыгымнарын исәпкә алу өчен, эчке суүткәргеч белән җиһазландырылган һәр бинада су үлчәү узеллары урнаштыру тәкъдим ителә.

Шулай ук гамәлдәге һәр скважинаны су үлчәү узелы белән тәэмин итү планлаштырыла.

Суүткәргеч корылмаларында СНиП 2.04.02-84 һәм СанПиН 2.1.4.1110-02 нигезендә санитар саклау зонасы булырга тиеш.

## 5. Су белән тәэмин итү чыганакларын санитар саклау зоналары.

Санитар саклау зоналары барлык су чыганакларында һәм хуҗалык-эчү билгеләнешендәге суүткәргечләрдә аларның санитар-эпидемиологик ышанычлылыгын тәэмин итү максатларында каралырга тиеш.

Су белән тәэмин итү чыганакларын пычранудан саклау максатларында «Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрне санитар саклау зоналары» СанПиН 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә өч поястан торган санитар саклау зоналары оештыру күздә тотыла:

Санитар саклау зоналарының беренче поясына скважина тирәсендәге 30 – 50 м радиустагы территория кертелә. Беренче пояс территориясе киртәләнә һәм төзекләндерелә, баш корылмаларда эшләмәүче затларга керү тыела.

Икенче һәм өченче чикләү режимнарының санитария саклау зоналары поясы. Икенче һәм өченче пояслар зонасына махсус эзләнүләр нигезендә «Су белән тәэмин итү чыганакларын һәм эчәргә яраклы суүткәргечләрне санитар саклау зоналары» СанПин 2.1.4.1110-02 таләпләре нигезендә су алуны ышанычлы санитар яклауны тәэмин итә торган территорияләр кертелә. Икенче һәм өченче пояслар территориясендә чикләнгән санитария режимы урнаштырыла.

## 6. Су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын үстерү юнәлешләре.

Үсешнең төп юнәлешләре:

1. Су белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын һәм өзлексезлеген арттыру.
2. Җитештерүчән булмаган су югалтуларның кимүе.
3. Объектларның санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килүен тәэмин итү.
4. Перспектив ихтыяҗны тәэмин итү өчен, челтәрләрне үстерү. Төп бурычлар: тузган суүткәргеч челтәрләрен Ø110÷63 мм, ПЭ100) этаплап реконструкцияләү һәм алыштыру, җиһазларны алыштырып, скважиналарны

капиталь ремонтлау, санитар саклау зоналарын төзү һәм суны исәпкә алу узеллары белән җиһазлау.

### 7. Кайнар, эчәргә яраклы, техник су белән тәэмин итү һәм куллану балансы.

Җирлекне су белән тәэмин итү системасы халыкны хуҗалык-эчү ихтыяҗлары өчен салкын су белән генә тәэмин итә. Кайнар су белән тәэмин итү йортларда индивидуаль рәвештә башкарыла, техник су белән тәэмин итү (су сибү, янгын сүндерү) шул ук системадан тәэмин ителә.

- **Су бирү (су белән тәэмин итү):** Су бирүнең гомуми тәүлеклек күләме халык санынннан (3370 кеше) һәм су куллану нормативыннан чыгып бәяләнә. Гамәлдәге скважиналарның агымдагы һәм перспективалы ихтыяҗларны каплау өчен суммар дебиты җитәрлек.
- **Куллану:** Суның төп күләме (якынча 95 – 98 %) халык тарафыннан хуҗалык-эчү ихтыяҗларына тотыла. Аз гына күләме йорт яны кишәрлекләренә су сибү һәм янгын куркынычсызлыгын (башняларда янгынга каршы су запасы) тәэмин итү өчен кулланыла. Бирелә торган суның шактый өлеше (бәяләүләр буенча 30-40% ка кадәр) югары дәрәҗәдә тузганлык аркасында челтәрләрдә югала.
- **Баланс:** Киләчәктә, агып чыгуларны бетергәннән соң, су бирү күләме перспективалы үсешне һәм сәгатьлек тигезсезлек коэффициентын исәпкә алып, халыкның факттагы куллануы белән корреляцияләнәчәк.

### 8. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү буенча тәкъдимнәр.

1. **Реконструкциләү һәм модернизацияләү:** Гамәлдәге артезиан скважиналарына капиталь ремонт (иске җиһазларны сүтү, суны кудыру, насосларны алмаштыру, оголовокларны ремонтлау).
2. **Челтәрләрне реконструкцияләү:** Купка, Адай авылында тузган сүүткәргеч челтәрләрен ПЭ100 SDR17 торбаларына этаплап алыштыру.
3. **Яңа төзелеш:** Торак пунктларның бөтен территориясен колачлау челтәрен үстерү. Зур Сәрдек авылында Басу урамында 2 км озынлыкта сүүткәргеч челтәрләр төзү планлаштырыла.
4. **Төзекләндерү:** Барлык скважиналарның санитар саклау проект зоналарын төзү, һәр скважинаны һәм эчке сүүткәргечле һәр бинаны су үлчәү узеллары белән җиһазлау.

### 9. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү буенча чараларның экологик аспектлар.

Чараларга табигатьне саклау һәм мохитне яхшырту характеры хас:

1. Су югалтуларны киметү җир асты су ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануга китерә.
2. Санитар саклау зонасын төзекләндерү һәм скважиналарны ремонтлау сулы горизонтларның потенциаль пычрануын булдырмый кала.

3. Заманча полиэтилен торбалар куллану системаның герметиклыгын арттыра, челтәрдәге суның пычрану һәм пычраткыч матдәләрнең грунтка үтеп керү куркынычын киметә.
4. Эшләр башкару чорында туфрак катламын саклау, эрозияне булдырмау һәм төзелеш чүп-чарын утильләштерү буенча чаралар күрергә кирәк.

## 10. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системалары объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә капитал салулар күләмнәрен бәяләү.

Капитал салулар күләме эшләнгән проект-смета документлары нигезендә төгәлләштерелергә тиеш. Алдан бәяләү чыгымнарны үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- 7 скважинага капиталь ремонт ясау.
- Берничә чакрымга сузылган суүткәргеч челтәрләрен реконструкцияләү һәм яңаны төзү.
- Су үлчәү узелларын төзү һәм санитар саклау зонасын төзекләндерү. Финанслауның планлаштырыла торган төп чыганагы булып, «Чиста су» федераль һәм республика программалары акчалары тора.

## 11. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларын үстерү күрсәткечләренең планлы күрсәткечләре.

Схеманы гамәлгә ашыру чорына (10 ел) планлы күрсәткечләр үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1. Челтәрләрнең тузуын 30 % тан да артык булмаган дәрәҗәгә кадәр киметү.
2. Транспортировка вакытында су югалтуны 10 – 15 % ка кадәр киметү.
3. Үзәкләштерелгән система гамәлдә булган зонада яшәүче 100 % халыкны сыйфатлы эчәр су белән тәэмин итү.
4. Барлык гамәлдәге чыганакларның санитар саклау зонасын төзекләндерү.
5. Суны исәпкә алу объектларын 100 % җиһазландыру.
6. Су белән тәэмин итү системасының ышанычлылыгын норматив күрсәткечләргә кадәр күтәрү.

## 12. Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системаларының ачыкланган хуҗасыз объектлары исемлеге (алар ачыкланган очракта) һәм аларны эксплуатацияләүгә вәкаләтле оешмалар исемлеге.

Зур Сәрдек авыл җирлеге территориясендә үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасының хуҗасыз объектлары ачыкланмады. Барлык объектлар (9 скважина, 10 су башнясы, суүткәргеч челтәрләр) аларны эксплуатацияләүгә вәкаләтле Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты милкендә һәм балансында тора.